ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**22.09.2020**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 1783**

2020/2021 елгы ягулык сезоны башлану турында

2020/2021 елның көзге-кышкы чоры башлануга бәйле рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә 2020 елның 24 сентябреннән ягулык чоры башлануын билгеләргә.
2. Зеленодольск муниципаль районының җылылык белән тәэмин итүче оешмаларына, үз балансында яки хуҗалык алып бару өчен торак фонды булган, милек формасына карамастан, предприятиеләре һәм оешмалары җитәкчеләренә, көн саен, 2020 елның 24 сентябреннән башлап, «ТР ЗМР ТКХ департаменты» МБУ югарыда күрсәтелгән объектларга җылылык бирү турында мәгълүмат тапшырырга тәкъдим итәргә.
3. Зеленодольск муниципаль районының предприятиеләре һәм оешмалары җитәкчеләренә, җылылык белән тәэмин итүче оешмаларына 2020 елның 5 октябренә кадәр җибәрү-көйләү эшләрен тәмамларга тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карарны ЗМР Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигына Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин